# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасының
«Ана даны - Материнская слава»
медален гамәлгә кую турында

Әлеге Закон күп балалы аналарны Татарстан Республикасының «Ана даны - Материнская слава» медале белән бүләкләүгә тәкъдим итү нигезләрен һәм тәртибен билгели.

1 статья. Гаиләгә һәм аналарга дәүләт ярдәме күрсәтү, ана булган хатын-кызны иҗтимагый тану һәм ана карата олы ихтирам тәэмин итү, балаларны тәрбияләү һәм күп балалы гаиләләрне социаль яклау өчен уңайлы шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасының «Ана даны - Материнская слава» медале (моннан ары - «Ана даны - Материнская слава» медале, медаль) гамәлгә куела.

2 статья. «Ана даны - Материнская слава» медале белән биш һәм аннан да күбрәк бала тапкан һәм тәрбияләгән аналар - Татарстан Республикасы гражданнары бүләкләнәләр.

Бүләкләүгә тәкъдим иткәндә күп балалы ананың үз балаларын тәрбияләүгә намус белән каравы исәпкә алына.

«Ана даны - Материнская слава» медале белән соңгы баласы бер яшькә җиткән һәм калган балалары исән булган аналар бүләкләнә.

«Ана даны - Материнская слава» медале белән бүләкләүгә тәкъдим иткәндә түбәндәге балалар игътибарга алына:

законда билгеләнгән тәртиптә ана уллыкка алган;

Ватанны яклаганда яисә хәрби хезмәтнең башка төрле вазыйфаларын башкарганда, йә кеше гомерен коткару буенча, законлылык һәм хокук тәртибен саклау буенча граждан бурычын үтәгәндә һәлак булучылар яисә хәбәрсез югалучылар, шулай ук күрсәтелгән хәлләрдә яралану, контузия алу, имгәнү яисә авыру аркасында йә хезмәттә имгәнү яисә һөнәри авыру аркасында, йә бәхетсез очраклар, афәтләр, табигый бәла-казалар аркасында вафат булганнар.

176

3 статья. Күп балалы аналарны «Ана даны - Материнская слава» медале белән бүләкләүгә тәкъдим итү турында предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар коллективлары, социаль тәэминат органнары, җәмәгать берләшмәләре һәм ассоциацияләре, җирле үзидарә органнары үтенеч юллый алалар.

Үтенеч юлламалары күп балалы ананың яшәү урыны буенча җирле администрациягә җибәрелә. Җирле администрация документларны караганнан соң Татарстан Республикасы Президентына җибәрә.

4 статья. «Ана даны - Материнская слава» медале белән бүләкләүгә бәйле мәсьәләләрне карау тәртибе һәм документлар исемлеге Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

5 статья. «Ана даны - Материнская слава» медале белән бүләкләү Татарстан Республикасы Президенты указы белән башкарыла.

6 статья. «Ана даны - Материнская слава» медален күп балалы анага Татарстан Республикасы Президенты яисә аның кушуы буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры йә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының башка җитәкчеләре тапшыра.

«Ана даны - Материнская слава» медале һәм аның таныклыгы бүләкләнгән ананың шәхсән үзенә тантаналы рәвештә тапшырыла.

7 статья. «Ана даны - Материнская слава» медале белән бүләкләнгәннәр законда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә өстенлекле ташламалардан һәм социаль гарантияләрдән файдаланалар.

Медаль белән бүләкләнүчеләргә Татарстан Республикасы Президенты билгели торган тәртиптә һәм күләмнәрдә бер мәртәбә акчалата бүләк бирелә.

8 статья. Бүләкләнүче вафат булган очракта, «Ана даны - Материнская слава» медале һәм аның таныклыгы истәлек буларак саклау өчен законнар нигезендә аның якын туганнарында кала.

9 статья. Табигый бәла-казалар нәтиҗәсендә йә бүләкләнүчегә бәйле булмаган башка хәлләрдә, дәүләт бүләген югалтмый калу мөмкинлеге булмаганда, «Ана даны - Материнская слава» медаленең дубликаты бирелергә мөмкин.

Бүләкләнүче гаризасы буенча медаль дубликатын һәм аның таныклыгын бирү турында үтенеч юлламасы бүләкне югалту сәбәпләрен тикшергәннән соң, җирле администрация тарафыннан кузгатыла.

Югалганнары урынына медаль һәм анын таныклыгы дубликатлары законда билгеләнгән тәртиптә бирелә.

177

10 статья. «Ана даны -Материнская слава» медаленең һәм аның таныклыгының тәртип номеры була.

11 статья. Татарстан Республикасының «Ана даны - Материнская слава» медаленең тасвирламасы кушымта итеп бирелә.

12 статья. Әлеге Закон матбугатта рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 6 декабре
№ 2492